МИНИСТЕРСТВО ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО УПРАВЛЕНИЯ, ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.02.2025 Казан ш. № п/35

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 елның 17 августындагы п/217 номерлы боерыгы белән расланган Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 августындагы п/217 номерлы боерыгы белән расланган Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2024 елның 2 августындагы п/159 номерлы, 2024 елның 25 ноябрендәге п/242 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша Республика порталында яисә Бердәм порталда тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы гаризага эшләр номенклатурасы һәм Республика порталында яисә Бердәм порталда шәхси кабинетта чагылдырыла торган

«Документларны тикшерү» статусы нигезендә номер бирелгән көннән алып биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон почта, почта аша яисә шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы гариза һәм документлар теркәлгән көннән алып биш эш көненнән дә артмый.»;

2.6.1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1.1. Россия Федерациясе гражданнары:

1) кәгазь чыганакта (рус телендә) (әлеге Регламентка 1 нче кушымта) яки Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган электрон документ (тиешле белешмәләрне интерактив формага кертү юлы белән тутырыла) формасында гариза;

2) шәхесне, гражданлыкны таныклаучы документларның төп нөсхәсе яисә күчермәсе, Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып гариза бирү очракларыннан тыш. Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

3) Бердәм портал һәм Республика порталыннан файдаланып гариза бирү очракларыннан тыш, алынган белем һәм (яки) алынган белем һәм квалификация документының оригиналы яки күчермәсе;

4) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон) 68 статьясындагы 4 өлеше нигезендә өстенлекле яисә беренче чиратта кабул итү хокукын раслый торган документның төп нөсхәсе яисә күчермәсе, Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә гариза бирү очракларыннан тыш.

5) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып гариза бирү очракларыннан тыш, 4 фотосурәт;

6) мөрәҗәгать итүче вәкиле (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ (ышанычнамә);

7) инвалидлыкны яисә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгәнлекне раслый торган белешмәләр (инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар тарафыннан тапшырыла);

8) сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 14 августындагы 697 номерлы карары белән расланган, укырга кергәндә укырга керүчеләр тиешле вазыйфа яисә белгечлек буенча хезмәт шартнамәсе яисә хезмәт контракты төзегәндә билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри алдан медицина тикшерүе (тикшерүе) уза торган белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча).

Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 1-8 пунктларында күрсәтелгән документлардан тыш, индивидуаль казанышларның нәтиҗәләрен раслый торган документларның төп нөсхәсен яисә күчермәсен, шулай ук максатчан укыту турында шартнамәнең максатчан укыту заказчысы тарафыннан таныкланган күчермәсен яисә күрсәтелгән шартнамәнең төп нөсхәсен күрсәтеп таныкланмаган күчермәсен бирергә хокуклы.

Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып гариза биргән очракта, мөрәҗәгать итүче белем турындагы документның һәм (яисә) белем турындагы һәм квалификация турындагы документның күчермәсен яисә белем турындагы документның һәм (яисә) белем турындагы һәм квалификация турындагы документның дубликатын, 273-ФЗ номерлы федераль законның 68 статьясындагы 4 өлеше нигезендә өстенлекле яисә беренче чиратта кабул итү хокукын раслый торган документның күчермәсен тапшыра. Мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариус, тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.

2.6.1.2 пунктның 3 пунктчасында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләрен «273-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.6.3[1] пунктын өстәргә:

«2.6.3[1] Мөрәҗәгать итүче җитешмәгән документларны гариза биргән вакыттан алып бер эш көне эчендә алмаштырырга һәм (яисә) кертергә хокуклы, түбәндәгеләр аша:

Гаризаны һәм беркетелгән документларны кәгазьдә биргәндә, – Учреждение аша;

электрон формада документлар тапшырганда, – Бердәм портал, Республика порталы аша.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булмаган документларны тапшыра алмый.

Мөрәҗәгать итүче ярдәм хезмәтенә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең теләсә кайсы этабында (843) 272-55-55 телефоны аша мөрәҗәгать итә ала.»;

2.6.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.9. «МЦК-КТИТС» ДАҺБУ, дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә түбәндәгеләрне соратып ала:

1) ышаныч кәгазе бирү һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр; Сорау Федераль нотариаль палатага, «Федераль нотариаль палата. Реквизитлар буенча ышанычнамәләрне тикшерү» сервисына юллана;

2) инвалидлык яисә сәламәтлек мөмкинлекләренең чикләнгән булуы турында белешмәләр – «Федераль инвалидлар реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы тарафыннан бирелә торган документлардагы белешмәләр. Сорау Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

3) сәламәтлек торышы турында белешмәләр. Сорау сәламәтлек торышы турында бәяләмә биргән медицина учреждениесенә җибәрелә;

4) алган белем турында һәм (яки) квалификация турында документлар, уку турында документлар турында федераль белешмәләр реестрында булган алган белем турында белешмәләр һәм (яисә) белем турында һәм (яисә) квалификация турында белешмәләр. Сорау Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәткә җибәрелә;

5) Россия Федерациясе гражданины паспортының гамәлдә булуы (яраксызлыгы) турында белешмәләр, чит ил гражданинына яки гражданлыгы булмаган затка вакытлыча яшәүгә рөхсәт бирү турында белешмәләр. Сорау Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына, «Россия Эчке эшләр министрлыгының сервис концентраторы» электрон сервисына җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша сорала торган документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән сорала торган документларның мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тормый.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.3.1[1] пунктын өстәргә:

«3.3.3.1[1] Шушы регламентның 2.7.1 пунктының 1-5, 7 пунктчаларында каралган нигезләр булганда, гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына, җитмәгән документларны алмаштыру һәм/яки тапшыру мөмкинлеген күрсәтеп, ирекле формадагы хәбәр җибәрелә. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге гамәлләрне мондый хәбәр җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә башкарырга тәкъдим ителә.»;

3.3.3.2 пунктының беренче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2.2. Шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда һәм мөрәҗәгать итүче 3.3.3.1[1] пункты нигезендә җитешмәгән документларны тапшырмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

3.3.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.3. Әлеге Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.1[1], 3.3.3.2 пунктларында күрсәтелгән процедуралар үтәлеше, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: карауга кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.».

Министр А.Р. Хәйруллин